Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Түбән Мактама бистә Советы

КАРАРЫ

27 октябрь 2022 ел №63

Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистә Советының 2018 елның 24 августындагы 132 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама шәһәр җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы тәртибе һәм шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыклары, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларын, депутатлар, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары һәм муниципаль хезмәткәрләрнең айлык вазыйфа окладларының акчалата бүләкләү күләмнәрен арттыру турында» карары нигезендә

Түбән Мактама бистә Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистә Советының 2018 елның 24 августындагы 132 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама шәһәр җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы тәртибе һәм шартлары турында»гы карарына (Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистә Советының 2018 елның 5 декабрендәге 139 номерлы, 2020 елның 11 декабрендәге 12 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. «Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама шәһәр җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы тәртибе һәм шартлары турында»гы карарга кушымтаның 6 пункт 2 пунктчасында, 7 пункт 3 пунктчасында «(авырлыгы, киеренкелеге, хезмәттә югары казанышлары, махсус эш режимы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 1 нче кушымтадагы таблицаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

Әлмәт муниципаль районы
Түбән Мактама шәһәр җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт окладлары күләме

| «Вазыйфа исеме» | Вазыйфа оклады |
|---|---|
| | 9 группа |
| Башкарма комитет җитәкчесе | 22242,00 |
| Бистә башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары | 21525,00 |

1.3. 2 нче кушымтадагы таблицаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама шәһәр җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының айлык акчалата бүләкләү күләмнәре»

| «Вазыйфа исеме» | Вазыйфа оклады |
|---|---|
| | 9 группа |
| Башлык | 22250,00 |
| Башлык урынбасары | 17745,00 |

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле финанс чыгымнары белән тәэмин итү тиешле елга җирле бюджетта каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Әлеге карарны Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе һәм Тихоновка авылы территорияләрендә урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, шулай ук "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында"(PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга

4. Бу карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистә башлыгы Р.А. Бадретдинов